**СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

| **РЕШЕНИЕ** | **КАРАР** |
|---|---|
| **9 октябрь, 2021ел** | **№ 113** |

## Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс игълан итү турында

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе Шәйдуллин Дамир Фәритович вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылуга бәйле рәвештә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 37 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 26 статьясы, Татарстан Республикасының муниципаль хезмәт турында кодексының 19 статьясы, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 51 статьясы нигезендә, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турында нигезләмә хакында» 2018 елның 11 июлендәге 227 номерлы Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы карарлары (19.10.2020 № 9, 15.09.2021 № 103 карарлары редакциясендә) нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс игълан итәргә һәм аны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының 2018 елның 11 июлендәге 227 номерлы карары (19.10.2020 № 9, 15.09.2021 № 103 карарлар редакциясендә) белән расланган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә ярашлы рәвештә уздырырга.

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучылардан конкурска документларны 2021 елның 14 октябреннән 2021 елның 03 ноябренә кадәр түбәндәге адрес буенча кабул итәргә: 422700, Татарстан Республикасы, Биектау муниципаль районы,

Кооператив ур., 5 йорт, ял һәм бәйрәм көннәреннән тыш, көн саен 8 сәгатьтән 17 сәгатькә кадәр.

2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә кандидатураларны карау өчен конкурс комиссиясе (алга таба - Конкурс комиссиясе) составын Татарстан Республикасы Президентының 2019 елның 19 июлендәге ПУ-419 номерлы «Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының башкарма комитетлары җитәкчеләре вазыйфаларын биләүгә кандидатураларны карау өчен конкурс комиссияләре әгъзалары исемлегенә үзгәреш кертү турында» Указын исәпкә алып расларга.

3. Конкурс комиссиясенә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә 2021 елның 10 нояберенә кадәр конкурс үткәрергә һәм конкурс нәтиҗәләре һәм кандидатлар турында Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советына мәгълүмат бирергә.

4. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү турында хәбәрне «Биектау хәбәрләре» район газетасында бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы рәисе урынбасары Ә.Ш. Шакировка йөкләргә.

Совет рәисе урынбасары,
муниципаль район башлыгы урынбасары Ә.Ш. Шакиров

Татарстан Республикасы
Биектау муниципаль районы
Советының 2021 елның
09 октябрендәге 113 номерлы
карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә кандидатураларны карау өчен конкурс комиссиясе составы**

1. Абрамов Артем Юрьевич - Татарстан Республикасы Президентының Территорияләр белән эшләү идарәсе баш киңәшчесе.
2. Заһидуллин Рөстәм Илдусович - Татарстан Республикасы юстиция министры.
3. Хәкимҗанов Ленар Сәетҗанович - Татарстан Республикасы мәдәният министры урынбасары.
4. Шакиров Әнәс Шәүкәтович - Биектау муниципаль районы Башлыгы урынбасары, Биектау муниципаль районы Советы депутаты, комиссия рәисе.
5. Архипов Владимир Димитриевич - район Советының юридик бүлеге башлыгы, комиссия рәисе урынбасары.
6. Гыйләҗева Алсу Габделхәевна - район Башлыгының коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча ярдәмчесе, комиссия секретаре.